ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР № 16

Урыссу ш. т.п. 15. 11. 2022 ел

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәтләре өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” карарына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2022 ел, №881 карары белән, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итте:

1. 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2018 елның 18 маендагы 10 номерлы карары белән расланган даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, айлык акчалата түләү күләмен 1,04 тапкырга арттырырга.

2. 2022 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмен алар биләгән муниципаль хезмәт вазифаларына ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2018 елның 18 маендагы “Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен

түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында" 10 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә Урыссу шәһәр тибындагы поселогында муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән төркеме белгеченең вазыйфаи окладны күләмен 1,04 тапкырга индексацияләргә һәм аны 13991,00 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»на урнаштыру һәм Ютазы муниципаль районының www.jutaza.tatar.ru веб-адрес буенча рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы рәисе,
Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин